ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29.06.2023 ел** **№ 837**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 04 февралендәге 100 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.3 пунктының беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3 Компенсация алуга хокукны билгеләгәндә, гаиләнең җан башына туры килә торган уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 03 декабрендәге 1095 карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023

елның 04 февралендәге 100 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән, кагыйдәләр буенча исәпләп чыгарыла.

Түләүне билгеләгәндә, гаиләнең уртача кереме гаилә әгъзаларының түләү билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан килүче соңгы 12 календарь айда керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин